РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 17 июне № 42

Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында

Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Баландин Денис Ивановичның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 5 пунктына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына таянып, Түбән Кама шәһәр Советының 2015 елның 27 апрелендәге 19 номерлы «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» карары белән, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.
2. Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъвачыга карата куелган таләпләрне расларга (кушымта).
3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең « Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында» 2020 елның 15 июнендәге 392 номерлы карарын исәпкә алып, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен түбәндәге составта алты кеше күләмендә конкурс комиссиясен расларга:

| | |
|---|---|
| Метшин<br>Айдар Рәис улы | - Түбән Кама шәһәре Мэры, комиссия рәисе; |
| Долотказина<br>Эльвира Рәфгать кызы | - Түбән Кама шәһәр Советы депутаты, комиссия рәисе урынбасары; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Нуретдинов<br>Илдар Наил улы | - Түбән Кама шәһәр Советы депутаты; |
| Сәйфетдинов<br>Айдар Габдуллаҗан улы | - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |

Беляев
Радмир Илдар улы

- Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

Бәдретдинов
Илнар Наил улы

- Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

4. Конкурска документларны 2020 елның 22 июненнән 11 июленә кадәр Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, 202 каб. адресы буенча урнашкан Советлар йорты бинасында 8 дән 17 сәгатькә кадәр, ял көннәреннән тыш, көн саен кабул итәргә, тел.42-42-66.

5. Конкурс комиссиясенә 2020 елның 13 июленнән 20 июленә кадәр Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә һәм конкурс тәмамланганнан соң өч көн эчендә конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Түбән Кама шәһәр Советына тапшырырга.

6. Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлегенә:

6.1. 2020 елның 19 июнендә массакүләм мәгълүмат чараларында Түбән Кама шәһәр Советының әлеге карарын, Түбән Кама шәһәре бшкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъвачыга карата куелган таләпләрне, конкурста катнашу өчен кирәкле документлар исемлеген, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проектын бастырып чыгарырга;

6.2. конкурста катнашу өчен дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны конкурс комиссиясенә кабул итүне, саклауны, тапшыруны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры — А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр
Советының
2020 елның 17 июнендәге
42 номерлы карарына кушымта

Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъвачыга карата куелган таләпләр

1. Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына кандидатның түбәндәгеләр булуы:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы;

б) эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары һөнәри белем;

в) 2 елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә дүрт ел эш стажы;

г) оешма, дәүләт органы, муниципаль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазыйфасында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында биш елдан да ким булмаган идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе.

2. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү Тәртибенә (алга таба – Тәртип) 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза тапшыра, аңа түбәндәге документлар беркетелергә тиеш:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән билгеләнгән форма буенча, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета һәм 3 х 4 см үлчәмле фотография;

2) автобиография;

3) паспортның яки аны алмаштыручы документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе (тиешле документ документларны тапшырганда һәм конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) Югары белем, эш стажы һәм квалификация булуны раслаучы документлар:

- гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

- һөнәри белем турында, шулай ук, граждан теләге буенча, өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе. Конкурсант өстәмә рәвештә аның һөнәри әзерлеген характерлаучы башка документларны да тапшыра ала;

5) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә.

Барлык чыганаклардан алынган керемнәр (элеке эш урыныннан яки сайланулы вазыйфа биләү урыныннан керемнәр, пенсияләр, пособиеләр, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр конкурска документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен, шулай ук мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә конкурска документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына торышында (хисап датасына) бирелә.

Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла;

6) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыруларның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

7) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы;

8) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

9) хәрби исәпкә алу документлары – запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен.

10) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләр.

3. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наймга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

И.Н. Нуретдинов